**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№7524**
**14.12.2018**

Башкарма комитетның «Ел эшмәкәре» шәһәр конкурсын үткәрү турында» 2018 елның 28 ноябрендәге 7074 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Уставының 41 маддәсе, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/7 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Ел эшмәкәре» шәһәр конкурсын үткәрү турында» 2018 елның 28 ноябрендәге 7074 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) «Ел эшмәкәре» конкурсын үткәрү турында нигезнамәдә:

- 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Конкурста үз эшчәнлекләрен Яр Чаллы шәһәрендә гамәлгә ашыручы, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына караган шәхси эшмәкәрләр, оештыручылар, бергә оештыручылар, юридик затларның җитәкчеләре катнаша ала».

- 7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Конкурсның «Ел старты» номинациясендә катнашуга 2018 елда Яр Чаллы шәһәрендә үз бизнесларын теркәгән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары чакырыла.

Конкурсның «Профессионал» номинациясендә катнашуга Яр Чаллы шәһәрендә теркәлгән һәм үз эшчәнлеген кимендә биш ел гамәлгә ашыручы, үсеш стратегиясенең тотрыклылыгын һәм нәтиҗәлелеген күрсәтүче кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары чакырыла.

Конкурсның «Мәрхәмәтле йөрәк» һәм «Уңышка юл» номинацияләрендә катнашуга предприятиенең теркәлү датасына бәйсез рәвештә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары чакырыла.»;

- нигезнамәгә кушымтаны әлеге карарга 1 нче кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә;

2) 2 нче кушымтаны әлеге карарга 2 нче кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2018 елның 14 декабрендәге
7524 нче карарына
1 нче кушымта

«Ел эшмәкәре»
конкурсы турында
нигезнамәгә кушымта

«Ел эшмәкәре» конкурсында катнашуга
заявка

номинацияләр:

| | | |
|---|---|---|
| 1. | «Ел старты» | ☐ |
| 2. | «Профессионал» | ☐ |
| 3. | «Мәрхәмәтле йөрәк» | ☐ |
| 4. | «Уңышка юл» | ☐ |

I. Конкурста катнашучы турында мәгълүмат:

1. Фамилиясе Исеме Атасының исеме ______________________
2. Электрон почтасы ___________________________
3. Элемтә телефоны _________________________
4. Компаниядәге вазыйфасы ______________________

II. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты турында мәгълүмат:

1. Оешманың исеме

2. Оештыру-хокукый формасы
☐ ШЭ
☐ ЮЗ
☐ Крестьян-фермерлык хуҗалыгы

3. ИНН:______________________________

4. Керем (сум)
2017 елда – __________
2018 елда (бәя) – _________

5. 2018 елның 9 аенда керемнең 2017 елның шул чоры белән чагыштырганда үсеш темплары (%) («Ел старты» номинациясеннән тыш, барысы өчен)

_____________________

Бизнес ачылган моменттан башлап айлар буенча керем динамикасы (сум, %) («Ел старты» номинациясе өчен)

____________________________

6. Хезмәткәрләр саны
2017 елда - _________
2018 елда - _________

7. Хезмәткәрләрнең уртача эш хакы (сум)
2017 елда - _________
2018 елда (бәя) - _________

8. Эш хакын хезмәткә түләүнең минималь күләменнән кимрәк түләү (2018 елның 1 маеннан хезмәткә түләүнең минималь күләме 11163 сумны тәшкил итә)

☐ бар

☐ юк

9. Агымдагы елда хәйрия эшчәнлегенә җибәрелгән акчаларның күләме (төп алучыларны күрсәтеп)

10. Интернет-тавыш бирү өчен эшчәнлекне (бизнесны) кыскача тасвирлау

_______________________________________

11. Шәхси мәгълүматны эшкәртүгә ризалык

☐ «Шәхси мәгълүматлар турында», 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ санлы Федераль закон таләпләре нигезендә, конкурсны оештыручыга минем тарафтан тапшырылган яки тапшырылачак минем шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә һәм өченче затларга тапшыруга үз ризалыгымны бирәм.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2018 елның 14 декабрендәге
7524 нче карарына
2 нче кушымта

Башкарма комитетның
2018 елның 28 ноябрендәге
7074 нче карарына
2 нче кушымта

«Ел эшмәкәре»
конкурсына әзерлек һәм аны үткәрү буенча оештыру комитеты
составы

| | |
|---|---|
| Кропотова Наталия Анатольевна | оештыру комитеты рәисе, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары |
| Балта Андрей Василевич | «Промвест» ПБ ҖЧҖ генераль директоры (килешенү буенча) |
| Бәшәров Фәрид Рәшид улы | «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре Сәүдә-сәнәгать палатасы» берлегенең генераль директоры (килешенү буенча) |
| Билалов Ринат Вагыйз улы | Бизнес онлайн-Закамье проекты җитәкчесе (килешенү буенча) |
| Гыйлаҗева Гүзәл Вәлиәхмәт кызы | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе башлыгы |
| Дербенева Татьяна Даниловна | «Аудит ТД» фирмасы ҖЧҖ генераль директоры (килешенү буенча) |
| Захарова Динара Айрат кызы | «Яшь эшмәкәрләр ассоциациясе» клуб берләшмәсе җитәкчесе (килешенү буенча) |
| Иванова Венера Бәхтегәрәй кызы | «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре Сәүдә-сәнәгать палатасы» берлеге Идарәсе каршындагы финанс комитеты рәисе (килешенү буенча) |
| Мөхәммәтҗанова Римма Равил кызы | Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе башлыгы |
| Никонов Тимур Викторович | «2ГИС-ЗАКАМЬЕ» ҖЧҖ директоры (килешенү буенча) |
| Сәгъдиев Айрат Сәгыйть улы | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе башлыгы урынбасары, эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү бүлеге башлыгы |

| | |
|---|---|
| Туктарова<br>Венера Надир кызы | «АКИБАНК» ААҖ идарә Рәисе урынбасары, Шәһәр Советы депутаты (килешенү буенча) |
| Шаһиева Гөлнар<br>Йосыф кызы | Татарстан Республикасы иҗтимагый палатасы әгъзасы, «Перспектива» гражданлык җәмгыяте институтларының үстерү һәм өстәмә белем бирү ресурс үзәге» автономияле коммерцияле булмаган оешмасы директоры (килешенү буенча) |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова